СОВЕТ
КОНОВАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423719,Республика Татарстан
Мензелинский район, с. Коноваловка, ул.
Центральная, 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОНОВАЛОВКА АВЫЛ СОВЕТЫ

423719, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Коноваловка авылы,
Центральная урамы,5

телефон: (85555) 2-34-47. E-mail Kval.Mnz@tatar.ru
ОКПО 92640440 ОГРН 1021605552803 ИНН/КПП 1628002812/162801001

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге составына кергән Белопахотный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**10 ноябрь, 2019 ел.** **№ 3**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Белопахотный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

- балалар уен мәйданчыгы элементларын сатып алу, урнаштыру;
- күл территориясен чистарту (агачларны кисү, күлне тирәнәйтү һәм чүп-чардан арындыру)
- чүплекне ликвидацияләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 35 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 25 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 25 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.